| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 123

Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турында электрон рәвештә белешмәләр формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 252 номерлы карары белән расланган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча күчермәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында «хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләрен «хезмәт кенәгәсе күчермәсе, һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 252 номерлы карары белән расланган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча күчермәләре бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында «хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләрен «хезмәт кенәгәсе күчермәсе, һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы)» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров